


# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 7 (10) ИЮЛЬ 2009


## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА




В селе Старокутлумбетьево Матвеевского района 27 июня 2009 года состоялся областной сабантуй и праздник татарской национальной культуры. Так же мероприятия были посвящены 265-летию этого старинного татарского села. Активное участие в сабантуе представителей Ютазинского района Татарстана, во главе с руководителем администрации, придало празднику особый национальный колорит. Гости приготовили красивые подарки, добротную культурную программу, заметно выделялись ютазинцы в торговых рядах. В тот же день сабантуй, совмещенный с Днем молодежи, прошел в Абдулино.



Активное участие в федеральном сабантуе, проходившем вначале июля в городе Ульяновске, приняли оренбуржцы. Делегацию из шестнадцати человек возглавил ответственный секретарь Асекеевской ТНКА Ришат Кутлукаев. Заметно выделялись в ней бугурусланцы и асекеевцы. Так, председатель Бугурусланского ТОЦ Хамзя Газизов обеспечил делегацию транспортом и привез на сабантуй борцов курэш. В целом программа была насыщенной и интересной.




Еще несколько ребят из Асекеевского района отдохнут в палаточной лагере в Татарстане, в смене, организованной молодежным центром «Идель». Цель — консолидация детей, проживающих в регионах Российской Федерации и странах СНГ, путем приобщения их к истории, культуре, традициям татарского народа и развития национального самосознания. В программе — обучение родному языку, истории, экскурсии в Казань и Билярск.

Президент РФ Дмитрий Медведев побывал в Московской соборной мечети. С ее посещения началась его встреча с духовными лидерами российских мусульман. Проблемы обсуждались от самых глобальных — таких, как отношения между конфессиями, до самых насущных — таких, как отопление сельских мечетей зимой. Входя в мечеть, любой мусульманин обязан снять обувь. Но и Дмитрий Медведев, прежде чем переступить порог молельного зала Московской соборной мечети, тоже разулся. Это, конечно, не только следование традиции, но, прежде всего, дань уважения к одной из крупнейших мировых религий и к ее российским последователям.

tatarlar.ru

ФОТОРЕПОРТАЖ

# МАРКИ АСЕКЕЕВСКОЙ

В живописном уголке красивого села Троицкое Асекеевского района расположен новый молочный цех ООО «Агрофирма Алга». Признаться, ожидал, что меня встретит характерный запах прокисшего молока, свойственный подобным предприятиям. Но здесь царила идеальная чистота и порядок. Мой гид, начальник цеха Н.Г.Ветренко, показывает мне технологию производства молочной продукции. В эти огромные танки сливается свежее молоко. Здесь сепарируется при необходимости, а здесь — готовая продукция, а здесь разливается в упаковки. В общем-то процесс сложный, технологически объемный, но занимает не так уж много места. Все оборудование современное, компактное и блестит хромированной чистотой.











Признаться, однажды я был в колбасном цехе одного города и надолго перестал быть любителем колбасы. Здесь же прекрасно оборудованные санузлы и душевые кабинки. Своя вкусная вода из скважины. Чистота, которой доверяешь.

Ужесточение требований и стандартов к молочной продукции требует соответствующей отдачи. Впрочем, Николай Григорьевич замечает, что самым требовательным проверяющим является сам генеральный директор ООО "Алга" Ильдус Давлятов.

Признаться, с трепетом берешь в руки продукцию с наклейкой «Асекеевское молоко». Это не чужие заграничные йогурты и ряженки с пластмассовым вкусом, а наше родное, домашнее. Наша продукция отправляется в Самару, магазины райцентра и другие районы области. Значит марке «Асекеевское молоко» — быть.




**На снимках:** лаборант-технолог Эльмира Багаутдинова проверяет качество ряженки; готовая продукция в руках Н.Г.Ветренко; прибыло свежее утреннее молоко.





МАСТЕР-КЛАСС

# ПЛАСТИЧЕСКОЕ ВОПЛОЩЕНИЕ НАЦИОНАЛЬНОГО ХАРАКТЕРА

Еще зимой, в рамках Ассоциации татарских национальных объединений «Бердәмлек», в селе Асекеево было решено провести мастер-классы для творческих детей и взрослых. Их инициатором стала директор Асекеевского Дома культуры Зайтуна Валишина. Её поддержали Председатель ТОЦ "Туган тел" г . Бугуруслан Х. Газизов, председатель культурно-просветительского общества "Туган тел" села Алькино Похвистневского района Р. Латыпов. Ну а генеральным спонсором программы стал председатель татарской национально-культурной автономии Асекеевского района, депутат Законодательного Собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов.





Вообще поиску молодых талантов у нас уделяется большое внимание. Такие межрегиональные фестивали, как «Ак хисләр», « Алтын көз», традиционно проводящиеся в селе Асекеево, призваны служить и этой цели. А вот непосредственно оттачивать мастерство талантливых ребят и призваны мастер-классы.

И вот в июле настал период воплощения планов в жизнь. Проводить мастер-класс приехал главный балетмейстер казанского театра юного зрителя, старший преподаватель гуманитарно-педагогического университета Венер Хамитов.

На это мероприятие приехали дети из Алькино и Бугуруслана, которым было обеспечено нормальное проживание в райцентре. Ну а местные ребята, все желающие учились вообще без проблем. Плата за обучение была чисто символической.

«Пластическое воплощение национального характера» — эта фраза точно и ёмко характеризует действо, воплощенное в мастер-классе. Известный танцор Венер Хамитов показал сельским ребятам, что такое танец. Как посредством движения, пластики показать поэзию песни без слов. Как результат — один из юных танцоров Ильгам Галлямов продолжит учебу в Казани.

«Восторг» — этим одним словом можно выразить все эмоции ребят — учеников

По итогам мастер-класса был поставлен концерт, в котором свое искусство показали и сам мастер, и приобщенные к танцу ребята.

**На снимках:** мастер Венер Хамитов со своими ученицами, снимок на память; Зайтуна Валишина представляет зрителям Ильгама Галлямова.

МОЛОДЕЖНЫЙ ФОРУМ

# Татар сандугачын ничек саклап калырга

## (татар телен сакларга һәм үстерергә тырышкан кешенең йөрәк авазы)



Татар дөньсында, бигрәк тә, милли-мәдәни автономияләр дәрәҗәсендә татар милли сәнгатен саклап калу проблемасы бик актуаль. Шуңа күрә милләтнең киләчәге, яшьләр өчен, күп чаралар үткәрелә. Мәсәлән, Россиянең төрле төбәкләрендә, республикаларда татар яшьләре оешмалары дөнья күрә. Бу оешмаларда җирлек дәрәҗәсендә актив эшләүче яшьләрне инде 19 ел буена "Идел"— яшьләр үзәге Казанда җыя. Яңа белем алу, тәҗрибә алышу өчен Татарстанның мәркәзендә, елга бер, бер атна дәвамында яшьләр очраша. 2009 ел аерылып тормады, "Татар яшьләре көннәренә" (ТЯК) 105 кеше җыелды, 32 регионнан, хәттә, Кытайдан да бер делегация бар иде. 5 июльдән алып, 12 июльгә кадәр яшьләр "Регина" кунакханәсендә, Казаннан ерак түгел генә булдылар.

Минем фикеремчә, "ТЯК" — ул бер атна дәвамында ләззәтләнеп, үзенең яшьтәшләре белән авыз тутырып татар телендә сөйләшергә мөнә дигән вакыт иде. Һәм бу минем иң зур алдану булды. Җыелган кешеләрдән, иң күбесе — сүзне аңлый торган, ләкин сөйләшми торган яшьләр, татарча гына сөйләшә, аңлаша торган яшьләр бик аз иде, ә инде унга якын кеше татарча бөтенләй аңламый торып "татар яшьләре" көннәренә килгәннәр. 6 июль көнне кунакханәнең конференц залында пресс — конференция узды. Яшьләр янына Региональ милли — мәдәни татар автономияләрнен җитәкчеләре һәм Федераль милли — мәдәни татар автономиянең рәисе Гилмутдинов Илдар Ирекович килгәннәр иде. Татар телендә барган сөйләшүләрне, залдан русча сүз кискәч, кунакларның гаҗәпләнүләрен күз алдыгызга китерә аласыздыр инде. Шундый хәлдә атна дәвам итте. Яшьләр белән үзләренең тәҗрибәсен уртаклашыр өчен кунакханәгә татар халкының бөек улларыда килгәннәр иде. Шулар арасында: Римзиль Вәлиев (журналист, "Азатлык" радиосы), Туфан Миңнуллин (язучы, драматург), Мингол Галиев (Татарстанның халык артисты), Мәгъсүм Гәрәев (журналист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе) һәм башкалар. Алардан аудиториягә беренче сорау "Кто не знает татарского языка?" иде. Биш — алты кул күтәрелсәдә, очрашу рус телендә дәвам итә. Бурятиядән, Нижний Новогородтан, Мордовиядән, Владимир, Омск, Новосибирск шәһәреннән татар халкының үзәгенә, Казанга русча сөйләшер өчен, нигә килеп йөрергә? Акрын гына, үз төбәгендә дә рус телендә аңлашып була бит.

Шуңа да булса, "татар яшьләре көннәре" — Татарстаннан читтә яшәп, милли кыйммәтләрне саклауда актив эшләүче татар яшьләре өчен. Һәм Казанга ялгыш эләгүче кеше булмаган дыр дип ышанасы килә. Кемдер Әстерханнар кебек татар дискотекаларына ике меңгә якын кеше җыя. Кемдер Мәскәү егетләре кебек, Корбан бәйрәменә малларны суеп, картларга, ятим балаларга тарата. Ләкин милләтнең киләчәге күбесе телдән тора. Татар телендә сөйләшә торган кеше калмаса, милләт тә үлә. Русификация, глобализация һәм катнаш гаиләләргә каршы торган шәхес, Туфан Миңнуллин, үз чыгышында афоризмлар гына кулланды дисәң дә була. "Татар телен белмәү — ул сезнең гаеп түгел, ул сезнең бәлә", "Бөек телләр юк дөньяда. Әгәр дә тел аркылы үзеннең гашыйк булганыны аңлата алсаң, бу тел бөек булып санала", "Дөньяда бер сандугач сайраса, аны тотып күптәннән үтереләр иде. Шундый ук хәл телләр белән дә".

Хәзер без, татар яшьләре көннәрендә катнашучылар, һәм гади, үз милләте өчен көрәшергә әзер торган кешеләр, шул татар сандугачын саклап калырга мәҗбүри. Аллага шөкер, бүгенге көндә, моның өчен бар мөмкинчелекләр дә бар, теләк кенә булсын. Бер генә теләк: галәмдә татар сандугачы тавышы бер кайчан да югалмасын.

**Алсу ХАФИЗ,**
**Тольятти шәһәре,**
**Иске Солтангол.**

**На снимке:** беседа с известным журналистом и писателем Римзилем Валеевым.

СЕМЬЯ

# ЗДЕСЬ ЦАРИТ СОГЛАСИЕ

В одном из последних номеров нашей газеты мы рассказывали об открытии татарского подворья в «Национальной деревне», в Оренбурге. Конечно, все было красиво: утварь, обстановка, стилизованная под старину. Не было одного — людей, проживающих в нем. А ведь главное украшение любого дома и подворье — люди, домочадцы. Поэтому зародилась идея, под рубрикой: «СемьЯ» рассказывать в нашей газете о семьях, служащих добрым примером. Наш первый рассказ о Шагвалеевых из села Асекеево.

Ахмет Валиевич и Рузалия Нурутдиновна познакомились еще в начале семидесятых. Она — учащаяся техникума, он — будущий шофер. А в 1973 году зародилась эта семья, и стали они работниками знаменитой тогда МПМК.

Тридцать шесть лет пролетели незаметно, теперь уж дети взрослые, внуки, а вот живет в этой семье любовь и уважение друг другу. И дети в восторге от родителей. Их дом — своего рода база. Я не случайно применил здесь слово из строительной терминологии. Ведь семьи Шагвалеевых — старших и их сына Ильдара занимаются реализацией строительных материалов.

Время, невзгоды, проблемы — по-разному действуют на людей. Для кого-то оборачиваются катастрофой, кто-то замыкается в себе и пьет горькую, а кто-то готов и может перевернуть страницу судьбы и начать все сначала.

Когда МПМК перестала существовать, Ахмет и Рузалия остались не у дел. А ведь надо растить детей, кормить семью. Рузалия подалась в «челноки», Ахмет добывал собственными руками строительный камень, песок и на своем стареньком ЗИЛу развозил и продавал нуждающимся этот стройматериал. Было очень тяжело, но Шагвалеевы рук не опускали. Потом Ахмет абы взялся привозить и продавать цемент и шифер. И, наконец, коммерческие способности и упорство в достижении цели вылились в создание собственного магазина стройматериалов. Вот уже пять лет эта торговая точка является общим семейным бизнесом Шагвалеевых старших — Ахмета и Рузалии и младших — Ильдара и Наили.



К ним в магазин приятно зайти. Всегда встретят с улыбкой, предупредительны, вежливы. Даже если ничего не надо, не хочется уходить без покупки.

Но не только работой жива семья, а и традициями. Здесь почитают старших. Мать и отец Ахмет абы до самой кончины жили в семье сына. Сейчас с ними проживает мама Рузалии апы. Дети, внуки постоянно бывают в доме родителей.

Дети — Гульнара с мужем Хусаином и Ильдар с Наилей построили собственные добротные дома. И в строительстве очень помогли родители. Внуки — Радик и Тимур, внучка Алина — чувствуют себя у дедушки с бабушкой, как дома.

Несмотря на то, что купить хлеб — не проблема, в доме Шагвалеевых сами пекут караваи. Аш, бәлеш, чәк-чәк, варенья, приготовленные Рузалей Нурутдиновной самые вкусные в мире — считают дети. Ахмет Валиевич рачительный хозяин. Все прибрано, все на месте во дворе, аккуратно, чисто, несмотря на то, что в надворных постройках хранятся стройматериалы. А «Газели» всегда на ходу.

Но не передать словами атмосферу в доме Шагвалеевых. Здесь царят дружба и согласие, почитание и уважение...

Алла ярдәм бирсен аларга!

**Ф.ГАЯЗЕТДИНОВ**

**На снимке:** семья Шагвалеевых.

ПРОБА ПЕРА



Мин 1958-че елның 22 июнендә Карамал авылында күп балалы татар гаиләсендә туып үстем. Бала чактан ук җыр-биюгә, шигырьгә гашыйк булып сәнгат түгәрәкләрендә актив катнаштым. Шуңа күрә эшемне дә сәхнә белән бәйләдем. Мәктәптә класс җитәкчебез һәм татар теле укытучысы Ахметшина Слу апабыз безгә үз-татар телебезне яратырга, хөрмәт итәргә, дөрес итеп татар телендә сөйләшергә һәм язарга өйрәтте. Аның җитәкчелегендә концертлар оештырып мәктәп сәхнәсендә дә чыгышлар ясый идек. Боларның барысы өчен дә мин Слу апага зур рәхмәтемне белдерәм.

Үземнең туган телемдә рәхәтләнеп сөйләшүемә, җырлый белүемә сөенеп бетә алмыйм.

Хәзер инде сөйләшү генә түгел, ә әкренләп, күңелемдә булган тойгыларымны, хисләремне шигырь юлларына да сала башладым. Шигырьләремне мин туган авылыма, әниемә, әтиемә, беренче мәхәббәтем-өзелеп сөйгән Карамал егетенә, дусларыма багышлап язам.

Бәлки алар кемнәрнеңдер күңелендә туган теленә, туган җиренә, татар халкыбызның асыл гореф — гадәтләренә карата җылы хисләр һәм мәхәббәт уятырлар дип өмет итәм.

## Карамалым минем

Бала чагым минем, җүләр чагым
Калды ерак, булмый кайтарып
Хәтер дигән моңлы бер зур тойгы
Куңелемне ташлый актарып.

Карамалым минем — йөрәк моңым
Һәрчак истә мәктәп елларым:
Белем биргән абый — апаларым,
Бергә үскән сердәш дусларым.

Тормыш мәшәкәте кочле икән
Теләсәң дә булмый очрашып,
Кыр казлары кебек төрле якка
Канат каккач аерылышып

Аң — белемем, җырым, моңым өчен
Рәхмәт сезгә мәктәп елларым,
Рәхмәт сезгә яшьлек дусларым,
Рәхмәт сиңа туган авылым!

Карамалым минем — йөрәк моңым,
Күңелемдә гел син — авылым!
Очрашулар әгәр насыйп булса
Кочагыңа кайтып авырмын!

## Әниләргә баш иям

Әниемнең сулышларын тоям
Баш очымда әле бүген дә
Кояш нурларыдай җылы иде
Назлы хисләр аның күзендә.

“Кызым” — дигән назлы сүзләр, иркәләүләр,
Әнием! Бәгърем! Мәңге исемдә
Әниләрдән кадерлерәк тагын
Кем генә бар бу җир йөзендә!?

Гомер уртасына җитер барам,
Инде үзем ана мин бүген
Тик шулай да, әнием ничек кирәк
Синең карашларың, синең һәр сүзең!

Син яраткан безне җир йөзенә
Өзеп алып бәгърең кисәген
Җәлләмәек дуслар әниләрдән
Йөрәкләрнең җылы хисләрен!

Күңелләрем минем изгелектә
Бурычлыбыз мәңге, мин беләм.
Әниләрдән күргән игелеккә
Алларында бүген баш иям!

**Марфуга ТАЗЕТДИНОВА. с.Асекеево.**

АКЦИЯ

## Имя малой родины

В прошлых номерах газеты мы объявили акцию «Имя малой Родины», чтобы рассказать о людях, которые вносят вклад в развитие Оренбургского края. О тех, кто, проживая за пределами Оренбуржья, своим трудом, научными открытиями, служением Отчизне и искусству превозносит имя малой Родины.

**Хуснутдинов Марат ХАЙРУТДИНОВИЧ** родился в 1937 г. в с.Асекеево Асекеевского района Оренбургской области, окончил Куйбышевский инженерно-строительный институт по специальности "инженер-гидротехник" в 1959 г., кандидат технических наук. Работал на различных должностях в тресте "Татспецстрой" и производственном объединении "Татнефтестрой"; 1972—1986 годах — заместитель министра строительства предприятий нефтяной и газовой промышленности СССР; 1986—1990 годах — советник по экономическим вопросам посольства СССР (Латинская Америка); с 1991 года — директор центра "Союзнефтегазстройтруд"; 1992—1993 годах — начальник Главного управления межгосударственных и межрегиональных отношений Министерства топлива и энергетики РФ; в 1993 году был назначен заместителем председателя Государственного комитета РФ по сотрудничеству с государствами СНГ; 1994—1998 — заместитель министра РФ по сотрудничеству с государствами — участниками СНГ; был заместителем председателя российской части Межправительственной комиссии по экономическому сотрудничеству между РФ и Республикой Узбекистан. Награжден двумя орденами Трудового Красного Знамени, орденом "Знак Почета", медалью "За доблестный труд".


## «Туган як» — газета твоего родного края!

Продолжается подписка с доставкой со следующего месяца на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край». **Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.** Концепция редакции — издание народной газеты, отвечающей пожеланиям жителей малых городов и сел.

### ДҮРТ СӘБӘП “ТУГАН ЯККА” ЯЗЫЛЫРГА!

**1.**Үзегез һәм якташларыгыз, бөтен татар дөньясы, курше районнар тормышы турында хәбәрләр укыйсыз.

**2.** Халкыбызның гөреф-гадәтләрен дин кануннарын өйрәнә аласыз, намаз вакыты күрсәтелә.

**3.** Үзегез язган теләкләрне, кинәшләрне, шигырьләрегезне, хикәяләрегезне бастыра аласыз.

**4.** Татар халык ризыкларын әзерләргә өйрәнәсез.

**ПОДПИСНОЙ ИНДЕКС 53167.** Оформить подписку можно в любом почтовом отделении или у почтальонов. Лучшие почтальоны будут поощрены материально. На газету можно подписаться с доставкой с августа месяца. **СПРАВКИ ПО ТЕЛЕФОНУ РЕДАКЦИИ: 8(35351) 222-81.**

## Авыл иртәсе

Бигрәк ямьле, хәтирәле
Җәен авыл иртәсе;
Авыл ташлап чит якларга
Бер дә килми китәсе.

Таң атканда кошлар сайрый
Су буенда, тирәктә;
Шул сайраган кош моңнары
Үтеп керә йөрәккә.

Мәчет ягыннан сузылып
Азан тавышы ишетелә;
Тирә-якны сокландырып
Безгә яңа көн килә.

Шул мизгелдә азган шайтан,
Пәриләр кереп кача, —
Авылдагы барча олы
Изге намазга баса.

Күптә үтми тау артыннан
Балкып кояш күренә;
Бакчадагы үскән гөлләр
Кояш нурына үрелә.

Урамнан тузан туздырып
Кырга көтү кузгала;
Тәмле йокыдан уянып
Елый сабый, бер бала.

Авыл халкы шәһәр кебек
Йокламый әле ярый;
Кемдер балыкка ашыга,
Кемдер бакчасын карый.

Эше барларны машина
Каядыр эшкә илтә;
Эшсезләр кибет янында
Ачылуын зарыгып көтә.

Авыл иртәсе җәйләрен
Көн дә шулай башлана;
Авылда яшәргә була,
Туган якны ташлама.

## Гомер

Кайчагында, эшләр юкта
Уйлар борчый күңелне;
Көннәр үтә, еллар уза
Картаябыз түгелме?

Кичә генә малай идек
Балык тотып йөрүче;
Бүген әйләндек кешегә-
Юкны-барны күрүче.

Кичә генә йөри идек
Кичен кызлар озатып;
Шул узган яшьлеккә берәр
Киләсе иде кайтып.

Теләсәктә белмибез
Алданиләр буласын;
Тәкъдир белән язмыш йөртә
Җирдә әдәм баласын.

Заяга үткән көннәргә
Уфтанмыйк әле бердә;
Яхшылары истә калсын
Начары очсын җилдә.

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН,**
**Иске Мөъмин авылы.**






## Салкын эчемлекләр

Әзерләү ысуллары һәм тәмнәре буенча эчемлекләр бик күп төрле була. Аларны яңа җыйган һәм кипкән җиләк-җимештән, бал, шикәр, арыш, арпадан, салат оны, арыш ипие, колмак яисә чүпрәдән әзерлиләр. Мондый эчемлекләрне өй шартларында әзерләү кыен түгел.

Ләкин шуны истә тотарга кирәк: яңа җыйган җиләк-җимеш эчемлекләрнен озак кайнатырга ярамый, югыйсә аларның витаминнары бик күп югала. Суыткан җиләк-җимеш эчемлекләренә теләгән кешегә лимон кислотасы да салырга мөмкин.

## Куе сосла

Арыш онын салат оны белән катнаштырырга (салат онын әзерләү: Арыш яки арпа алырга, салкын суда югач, өстен каплап җылы урынга куярга. Корырак булса, арышка су бөркергә. Берничә көннән орлык шыта башлый. Шыткан орлыкны юка гына итеп калайга җәеп духовкада киптерергә һәм тарттырырга) да сыек кына камыр изәргә, юган башак яисә вакланган салам өстәргә; боларның барысын да яхшылап болгатырга һәм чиста итеп юган балчык чүлмәкләргә тутырырга (сосланы агызып алу өчен чүлмәк стеналарына төпләреннән ике бармак биеклегендә тишек тишәргә һәм аны агач бөке белән әйбәтләп бөкеләргә кирәк). Камырлы чүлмәкне эссе мичкә куеп бер тәүлек тотарга. Мич суынмасын өчен аның капкачын балчык белән сыларга кирәк. Мичтә камыр пешә. Чүлмәкләрне мичтән алып кайнар су салырга һәм өсләрен каплап 3-4 сәгать тотарга. Пешеп кипкән камыр җебеп сыеклангач, чүлмәкләрне өстәлгә куярга һәм бөкеләрен ачып сосланы киң улактан кечкенә имән кисмәккә агызырга. Барлык чүлмәкләрдәге сосла да кисмәккә тутырыла. Әзер сосла кызыл төстә, куе, баллы була. Эчемлек тутырган кисмәкне салкынга куярга кирәк. Сосла табынга касәгә яки чынаякка салып бирелә.

Сосладан бушаган чүлмәккә тагын бер тапкыр кайнар су тутырырга мөмкин. 2-3 сәгатьтән чүлмәктә янадан, тик инде бу юлы сыеграк, сосла өлгерә. Анысын квас әзерләү өчен файдаланырга мөмкин.

## Квас

Квасны сыек сосладан да һәм шулай ук арыш ипиеннән дә әзерләргә була.

Арыш ипиен телемләп кисеп табага яки калайга тезәргә дә мичкә яисә духовкага куеп киптерергә. Аз гына көйгән бу сохарины имән кисмәккә салырга, аннары кайнар су тутырырга һәм өстен капларга. Төнәтмә бүлмә температурасына кадәр суынгач, аңа алдан аерым савытта пешереп суыткан колмак яки җылы суда изгән чүпрә салырга. Бер тәүлектән соң төнәтмәне, нечкә иләктән яки марлядан сөзеп, салкынга куярга.

Чемердәп торсын өчен төнәтмәгә бодай онынннан әчеткән апара салалар. Теләгән кешегә кваска колмак яисә чүпрә (яки апара) белән бергә шикәр, юал да өстәргә мөмкин. Тәмлерәк булсын өчен, йөзем җимеше дә салалар.

Апара өстәмичә генә ясаган квас кызгылт төстә, әчкелтембаллы була.

10 литр суга: 1-1,2 кг арыш ипие, 200-300 г чүпрә яки 200-300 г колмак, 450-550 г шикәр комы я бал.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное)

| АВГУСТ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-43 | 6-43 | 15-10 | 20-35 | 22-35 | 24-05 |
| 2 | 5-45 | 6-45 | 15-10 | 20-33 | 22-33 | 24-03 |
| 3 | 5-47 | 6-47 | 15-10 | 20-31 | 22-31 | 24-01 |
| 4 | 5-49 | 6-49 | 15-10 | 20-29 | 22-29 | 23-59 |
| 5 | 5-50 | 6-50 | 15-10 | 20-27 | 22-27 | 23-57 |
| 6 | 5-51 | 6-51 | 15-10 | 20-25 | 22-25 | 23-55 |
| 7 | 5-53 | 6-53 | 15-10 | 20-23 | 22-23 | 23-53 |
| 8 | 5-55 | 6-55 | 15-10 | 20-21 | 22-21 | 23-51 |
| 9 | 5-57 | 6-57 | 15-10 | 20-19 | 22-19 | 23-49 |
| 10 | 5-58 | 6-58 | 15-10 | 20-17 | 22-17 | 23-47 |
| 11 | 6-00 | 7-00 | 15-10 | 20-15 | 22-15 | 23-45 |
| 12 | 6-02 | 7-02 | 15-10 | 20-13 | 22-13 | 23-43 |
| 13 | 6-04 | 7-04 | 15-10 | 20-11 | 22-11 | 23-41 |
| 14 | 6-06 | 7-06 | 15-10 | 20-09 | 22-09 | 23-39 |
| 15 | 6-07 | 7-07 | 15-10 | 20-07 | 22-07 | 23-37 |
| 16 | 6-08 | 7-08 | 15-10 | 20-05 | 22-05 | 23-35 |
| 17 | 6-10 | 7-10 | 15-10 | 20-03 | 22-03 | 23-33 |
| 18 | 6-12 | 7-12 | 15-10 | 20-01 | 22-01 | 23-31 |
| 19 | 6-14 | 7-14 | 15-10 | 19-58 | 21-58 | 23-28 |
| 20 | 6-15 | 7-15 | 15-10 | 19-56 | 21-56 | 23-26 |
| 21 | 6-17 | 7-17 | 15-10 | 19-54 | 21-54 | 23-24 |
| 22 | 6-19 | 7-19 | 15-10 | 19-52 | 21-52 | 23-22 |
| 23 | 6-21 | 7-21 | 15-10 | 19-50 | 21-50 | 23-20 |
| 24 | 6-23 | 7-23 | 15-10 | 19-47 | 21-47 | 23-17 |
| 25 | 6-24 | 7-24 | 15-10 | 19-45 | 21-45 | 23-15 |
| 26 | 6-26 | 7-26 | 15-10 | 19-43 | 21-43 | 23-13 |
| 27 | 6-28 | 7-28 | 15-10 | 19-40 | 21-40 | 23-10 |
| 28 | 6-30 | 7-30 | 15-10 | 19-38 | 21-38 | 23-08 |
| 29 | 6-32 | 7-32 | 15-10 | 19-35 | 21-35 | 23-05 |
| 30 | 6-33 | 7-33 | 15-10 | 19-33 | 21-33 | 23-03 |
| 31 | 6-34 | 7-34 | 15-10 | 19-31 | 21-31 | 23-01 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут. (Время летнее).**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**УЧРЕДИТЕЛЬ:** ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:** С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81
**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.

Цена свободная. ТИРАЖ: 1000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**